МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** 26.01.2024

**БОЕРЫК** № 8-ОД

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 16 ноябрендәге 186-ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 5 сентябрендәге 1076 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы иҗтимагый шура турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 16 ноябрендәге 186-ОД номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2021 елның 23 ноябрендәге 214-ОД номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 31-ОД номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.»;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 186-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары каршындагы» сүзләре белән алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Иҗтимагый совет үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

1.3 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары каршындагы» сүзләре белән алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы белән Министрлык тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив

хокукый актлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Республика  башкарма хакимият органнарында эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган  норматив хокукый актларның проектларына һәм Министрлыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрелә торган норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирү максатларында да үткәрелә.».

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында законнарда билгеләнгән срокта дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны әлеге боерыкны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары Р.М.Карповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В.Коробченко